**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2023елның 31 гыйнвары** **13-РС номер**

## КАРАР

### Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2022елның 01 декабрендәге 10-53/13515 номерлы Пелев авыл җирлегенең генераль планы проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсен, 2023елның 20 гыйнварындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне карап., Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2021елның 9 августындагы 58-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын расларга (1 кушымта).
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән)көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**